УДК 631.95

*Җ.И. Фәйзрахманов*

# ФӘНГӘ ЯҢАЛЫК КЕРТҮЧЕ
## (профессор Ф.С. Сибәгатуллинның фәнни мирасы)

Статья посвящена многогранной деятельности известного ученого, доктора ветеринарных наук, профессора и члена-корреспондента Академии наук Республики Татарстан, внесшего большой вклад в развитие сельского хозяйства и ветеринарии региона Фатиха Саубановича Сибагатуллина. В статье отражено его успешное совмещение научных исследований с административной работой, занимая такие важные должности, как министр сельского хозяйства и советник Президента РТ по экологии. Его научное наследие насчитывает 93 публикации, среди которых монографии и учебные пособия. Фатих Саубанович активно сотрудничал с различными научными учреждениями, способствовал внедрению новых технологий в животноводстве. Так в статье описывается его уникальный подход к обучению студентов. Он был известным преподавателем, давая знания студентам Казанского государственного аграрного университета и вдохновляя их на любовь к животным. Его работа в области молочного животноводства и участие в разработке национальных проектов по развитию агропромышленного комплекса оставили заметный след в аграрной науке Татарстана.

**Ключевые слова:** ученый, профессор, эколог, преподаватель, новатор в науке, целеустремленный, талантливый организатор, внимательный наставник, тенденции научно-технического прогресса.

The article is devoted to the diverse activities of the famous scientist, Doctor of Veterinary Sciences, Professor and Corresponding Member of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, who made a great contribution to the development of agriculture and veterinary medicine in the region, Fatih Saubanovich Sibagatullin. The article reflects his successful combination of scientific research with administrative work, holding such important positions as Minister of Agriculture and Advisor to the President of the Republic of Tatarstan on Ecology. His scientific legacy includes 93 publications, including monographs and textbooks. Fatih Saubanovich actively collaborates with various scientific institutions, promotes the introduction of new technologies in animal husbandry. Thus, the article describes his unique approach to teaching students. He was a famous teacher, giving knowledge to students of the Kazan State Agrarian University and inspiring them to love animals. His work in the field of dairy farming and participation in the development of national projects for the development of the agro-industrial complex left a noticeable mark on the agricultural science of Tatarstan.

**Keywords:** scientist, professor, ecologist, teacher, scientific innovator, goal-oriented, talented organizer, attentive mentor, trends in scientific and technological progress.

Сибәгатуллин Фатих Сәүбән улы (01.05.1950–24.06.2023) – ветеринария фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы, Халыкара мәгълүматлаштыру академиясе, «Европа-Азия» Халыкара гуманитар академиясе

академигы, 2021 елдан Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнехановның экология буенча киңәшчесе.

Фатыйх Сәүбән улы Сибәгатуллин 1950 елның 1 маенда Татарстан АССР Кызыл Юл (хәзерге Арча) районының Апаз авылында туа. 1958–1965 елларда Апаз сигезьеллык мәктәбендә, 1965–1967 елларда Шушмабаш урта мәктәбендә укый. 1968 елда Казан ветеринария институты студенты була. 1983 елда Саратов югары партия мәктәбен тәмамлый.

1966 елда Арча районының «Ватан» совхозы эшчесе сыйфатында, хезмәт юлын башлап җибәрә. 1973–1974 елларда – Яшел Үзән районы «Бишнә» совхозында баш ветеринария табибы. 1974–1976 елларда – Балтач районы Чапаев исемендәге колхозда ветеринария табибы. 1976–1980 елларда – Балтач районы «Правда» колхозы рәисе.

1980 елда ул партия эшенә күчә. КПССның Балтач райкомы икенче секретаре (1980–1983) һәм Арча районы башкарма комитеты рәисе урынбасары (1983–1984) вазифаларын башкара. 1984–1990 елларда КПССның Мамадыш райкомы беренче секретаре була.

1990–1995 елларда – Татарстан Репубпликасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры. 1993 елда Казан ветеринария институтында «Базар икътисадына күчү чорында республиканың ветеринария хезмәтен камилләштерү» темасына диссертация яклап, ветеринария фәннәре кандидаты була. 1995 елда «Татарстан Республикасында ветеринария эшен оештыруны камилләштерү» темасына докторлык диссертациясен уңышлы яклый.

1996–2005 елларда – Нурлат (Октябрь) районы һәм Нурлат шәһәре администрациясе башлыгы, шулай ук халык депутатларының район советы президиумы рәисе.

2000–2004 елларда – II чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт советы депутаты. 2005 елда Казан дәүләт финанс-икътисад институтын тәмамлый. 2006–2007 елларда Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре башлыгы, шулай ук даими булмаган нигездә муниципаль район башлыгы булып эшли. «Татнефтепром-Зюзеевнефть» АҖ Директорлар советы рәисе һәм «Татнефтепром» АҖ Директорлар советы әгъзасы.

Фатих Сибәгатуллин 2008 елда РФ Дәүләт думасы депутаты итеп сайлана. Ул – кайда гына эшләсә дә, үзеннән соң якты эз калдырган шәхес.

Фатих Сәүбән улы озак еллар дәвамында зур административ эшне фәнни-тикшеренү эшчәнлеге белән янәшә алып бара, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Н.Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе, Казан дәүләт аграр университеты, Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты һәм башка фәнни учреждениеләр белән тыгыз хезмәттәшлектә, галимнәр коллективларын берләштерергә омтылып яши. Шуның матур үрнәге – икътисад фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы, югары мәктәп Халыкара

фәннәр академиясе хакыйкый әгъзасы, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе, Казан дәүләт аграр университеты ректоры Җәүдәт Ибраһим улы Фәйзрахманов белән озак еллар дәвам иткән фәнни һәм иҗади хезмәттәшлек.

Фатих Сәүбән улы 1999–2023 елларда Казан дәүләт аграр университетының «Терлекчелек продукциясен җитештерү һәм эшкәртү технологиясе» кафедрасында эшли. 1999 елда Нурлат шәһәрендә Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясенең филиалы ачыла. Бу эштә дә ул башлап йөрүчеләрнең берсе була. Үсемлекчелек һәм терлекчелек буенча практик дәресләр Нурлат районының иң алдынгы хуҗалыкларында үткәрелә. Татарстан Республикасы ипподромы һәм ат спорты музеенда Ф.С. Сибәгатуллин Казан дәүләт аграр университетының өлкән курс студентлары белән «Ветеринария нигезләре һәм хайваннарны үрчетү биотехникасы», «Терлекчелек экологиясе», «Атчылык» буенча дәресләр үткәрә. Фатих Сәүбән улы үзе атларны бик яраткан. Студентлар белән эшләгәндә дә, ул аларның иң элек атларны яратуына ирешүне максат итә. Ул чын мәгънәсендә үз эшенең остасы була.

Фатих Сәүбән улы авыл хуҗалыгы җитештерүен, шул исәптән сөт терлекчелеген үстерүгә дә үзеннән зур өлеш кертә. «2010 елга кадәр Татарстан Республикасында агросәнәгать комплексын үстерү» өстенлекле милли проектын һәм «2008–2012 елларга Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгын үстерү» республика максатчан программасы авторларының берсе. Ул Татарстан Республикасында терлекчелекне үстерү концепциясен эшләүдә дә катнаша. Республиканың Авыл хуҗалыгы министрлыгы белгечләре белән бергә «Ак Барс Агро» ҖЧҖ, «Красный Восток» ААҖ, «Сөләйманов» КФХ һәм Россия Федерациясенең башка мегафермаларында аның төп нигезләмәләрен гамәлгә ашыру буенча фәнни-методик җитәкчелекне үз кулына ала.

Ф.С. Сибәгатуллин – 93 фәнни эш, шул исәптән терлекчелек һәм ветеринариянең төрле мәсьәләләре буенча 4 монография, шулай ук 5 уку әсбабы авторы. Казан дәүләт аграр университетында аның җитәкчелегендә бер кандидатлык диссертациясе яклана.

Ф.С. Сибәгатуллин Казан дәүләт аграр университеты Гыйльми советы тарафыннан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең авыл хуҗалыгы фәннәре бүлегенә «Авыл хуҗалыгы фәннәре» белгечлеге буенча академиклыкка кандидат итеп күрсәтелә.

Эшчәнлегенең соңгы елларында А. Арбузов исемендәге Органик һәм физик химия институты белән берлектә «Терлекчелек калдыкларын утильләштерү өчен биологик активаторлардан файдалану» темасына фәнни тикшеренүләр үткәрә, аерым алганда, «Мефосфон» препараты (фосфин кислотасының бис(оксиметил) тозы) ярдәмендә хайваннар тиресен һәм кош тизәген куркынычсыз һәм тизләтелгән ферментацияләү ысулын һәм аннан нәтиҗәле файдалану юлларын эзли.

Ф.С. Сибәгатуллин һәм аның җитәкчелегендәге фәнни коллектив үткәргән тикшеренүләр нәтиҗәсендә тавык тизәген «Мефосфон» препараты белән зарарсызландыруның нәтиҗәлелеге исбатлана:

– тизәкнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысы киметелә, тизәкнең куркынычлык классы III дәрәҗәдән IV гә кадәр төшә;

– тизәкне ферментацияләү процессы тизләтелә, нәтиҗәдә аның агулылыгы 1,7 тапкыр кими;

– эчәк таягы төркемендәге бактерияләр (ЭТТБ) саны һәм энтерококклар 1,8 тапкыр кими.

Шулай ук тавык тизәгеннән «Компост «ПУ–1» органик ашламасы алу өчен «Мефосфон» препаратын куллануның нәтиҗәлелеге билгеләнә.

1. Компостлаштырганда «Мефосфон» препаратын куллану микроблар комплексының активрак эшләвен тәэмин итә, тизәкнең «өлгерү» вакытын кыскарта, әйләнә-тирә мохиткә аның зарарлы йогынтысын киметә, аксымнарның тизрәк һәм тулырак таркалуына, аммиак бүленеп чыгуга һәм тирәлекне оптималь дәрәҗәдә селтеләндерергә ярдәм итә. Димәк, ГОСТ 53117-2008 таләпләренә тулысынча туры килгән һәм составында патоген микрофлора булган «Компост «ПУ-1» органик продукты барлыкка килә.

2. «Йолдыз» сортлы сабан бодаен үстергәндә «Компост «ПУ-1» продуктын органик ашлама сыйфатында куллану:

– орлыкларның шытып чыгуын арттырырга булыша;

– үсемлекләрнең үсеш процессын яхшырта (тулысынча өлгергән очракта башак озынрак була);

– җыелган ашлык күләмен арттыра;

– бөртекнең сыйфатын (пыяласыманлыгы, җилемчә микъдары, аксым микъдары) яхшырта.

Шулай итеп, «Мефосфон» биологик активаторы ярдәмендә тиресне, кош тизәген утильләштерү, алга таба авыл хуҗалыгында югары нәтиҗәле органик ашлама буларак кулланылып, максатчан продукт алу ысулы булырга мөмкин, дип раслап була. Бу туфракның уңдырышлылыгын, авыл хуҗалыгы культураларының уңышын күтәрергә һәм тулаем экологик хәлне яхшыртырга мөмкинлек бирәчәк.

Галимнәр төркеме тарафыннан эшләнгән тизәкне зарарсызландыру технологиясенә дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсе бар. 2017 елдан, биологик актив «Мефосфон» препаратын кулланып, терлекчелек калдыкларының хәвефлелек «классын киметү»нең килештерелгән технологик регламенты эшләнә. Препаратны куллануның максатка ярашлылыгы Россия Федерациясе Табигый байлыклар һәм экология министрлыгы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан раслана.

Фатих Сәүбән улы – фәндә новатор, максатчан һәм сәләтле оештыручы, игътибарлы остаз була. Кайда гына эшләмәсен, патриотлыгы, зур җаваплылык хисе, эшкә ихлас бирелгәнлеге белән аерылып тора. Барлык дәүләт вазифаларында да ул фән-техника прогрессы тенденцияләрен гамәлгә ашырырга омтыла.

Ф.С. Сибәгатуллин Россия Федерациясе Дәүләт думасының Экология һәм әйләнә-тирә мохитне саклау комитеты әгъзасы, Гуманитар

фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы һәм Россия Федерациясе Федераль собраниесе Дәүләт думасының Табигый ресурслар, табигатьтән файдалану һәм экология комитеты әгъзасы, углеводород чималы комитеты рәисе, Россия Федерациясе Федераль собраниесе Дәүләт думасы депутаты буларак зур иҗтимагый эш алып бара.

Фатих Сәүбән улы Сибәгатуллин Казан дәүләт аграр университетындагы хезмәттәшләре хәтерендә хезмәт кешесе, галим һәм Татарстан Республикасының лаеклы гражданины булып сакланыр. Аның командада эшли белүе, лидерлыгы, профессиональлеге уңышлы эшчәнлегенең нигезенә ята һәм олы ихтирам хисе уята. Озак еллар дәвамында Ф.С. Сибәгатуллин кафедрада авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, профессор, Россия табигать фәннәре академиясе академигы Г.С. Шәрәфетдинов һәм авыл хуҗалыгы фәннәре докторы, доцент Р.Р. Шәйдуллин җитәкчелегендә нәтиҗәле эшли.

Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгын үстерүгә, кырларның һәм фермаларның продуктлылыгын арттыруның фәнни проблемаларын эшләүгә, үсемлекчелектә һәм терлекчелектә заманча технологияләрне гамәлгә кертүгә зур өлеш керткән өчен Ф.С. Сибәгатуллин Россия табигый фәннәр академиясе «Агросәнәгать комплексының фәнни проблемалары» бүлеге хакыйкый әгъзасы итеп сайлана (1996).

1997 елда аңа «Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә, 2000 елда ул Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт премиясе лауреаты була. Биология фәне һәм авыл хуҗалыгы өлкәләрендәге уңышлары өчен аңа Н.И. Вавилов исемендәге көмеш медаль (2001), Халыклар Дуслыгы ордены (1986 ), «Почёт билгесе» ордены (2002), «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены (2007), шулай ук IV дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» ордены, «Россиянең агросәнәгать комплексын үстерүгә керткән өлеше өчен» алтын медале, «Россия агросәнәгать комплексын үстерүгә керткән өлеше өчен» көмеш медале, «Казанның 1000 еллыгы» медале һәм башка күпсанлы дәүләт бүләкләре тапшырыла, шул исәптән ул – «Авыл хуҗалыгындагы казанышлары өчен» ордены кавалеры да (Франция, 1994).

Казан дәүләт аграр университетының тарих музеенда Фатих Сәүбән улы Сибәгатуллинга багышланган стенд күпсанлы тамашачыларның игътибарын җәлеп итә. Анда галимнең хөкүмәт бүләкләре, мактау грамоталары, китаплары һәм фотосурәтләре куелган.

***Фәйзрахманов Җәүдәт Ибраһим улы,***
*икътисад фәннәре докторы, профессор,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хакыйкый әгъзасы*

***Файзрахманов Джаудат Ибрагимович,***
*доктор экономических наук, профессор, действительный член Академии наук Республики Татарстан*

*marat-kmn@yandex.ru*